РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«11» март 2021 г. г. Альметьевск № 39

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы территориясендә җир кишәрлекләрен бирү нормалары турында» 2016 елның 29 апрелендәге 64 номерлы карарының үз көчен югалтуын тану хакында

Россия Федерациясе Җир кодексының 11.9 статьясындагы 1 пункты, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 38 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы уставы нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы территориясендә җир кишәрлекләрен бирү нормалары турында» 2016 елның 29 апрелендәге 64 номерлы карарының үз көчен югалткан дип танырга
2. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту район Советының икътисади үсеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм муниципаль милек мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләнә (Минһаҗев И.М.).

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов

«СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА»

Заказ № 2625